**2020 елда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карау нәтиҗәләре турында.**

Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» гы Федераль Закон (2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» гы Татарстан Республикасы Законы (2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ ), Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Положение турында» 2018 елның 14 июнендәге 97 номерлы Әлкәй авыл җирлеге Советы карары белән башкарыла.

Гражданнарны шәхси кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башлыгы тарафыннан атна саен сишәмбе 14.00 - 17.00 сәгатьләрдә, шәхсән алдан язылу буенча башкарыла.

Кабул итү көне һәм сәгатьләре, алдан язылып кую өчен телефоннар турында мәгълүмат Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырыла http://aznakayevo.tatar.ru әлеге мәгълүмат шулай ук җирле үзидарә органының Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44А нчы йорт адресы буенча урнашкан административ бинасында мәгълүмат стендларында урнаштырыла .

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге җирле үзидарә органында (алга таба – җирле үзидарә органы) гражданнарны кабул итүнең язылу һәм исәпкә алуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге сәркәтибе алып бара, ул гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен җаваплы.

2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 нче декабренә кадәр Әлкәй авыл җирлеге адресына 11 мөрәҗәгать кабул ителде .

Шулардан: язма - 0, телдән-10; район депутаты кабул итүе -1

Коллектив мөрәҗәгатьләр булмады.

Барлык телдән мөрәҗәгатьләр татар телендә (100 %)

Мөрәҗәгатьләрнең авторлары-пенсионерлар -27,27 %, бюджет өлкәсе хезмәткәрләре – 63,63 %, шәхси эшмәкәрләр – 0%.

Территориаль билге буенча барлык мөрәҗәгатьләр авыл җирлегендә яшәүчеләргә туры килә.

Мөрәҗәгатьләрнең тематикасын төзекләндерү (урамнарны яктырту, су буенча, территорияне төзекләндерү, йорт хайваннарын иректә йөртү, халыкны социаль тәэмин итү буенча) мәсьәләләре тәшкил итә .

Әлкәй авыл җирлегенә гражданнардан кергән язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең санынннан (11 мөрәҗәгать) барысына уңай чаралар һәм карарлар кабул ителде.

Авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова